**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 24 март № 164

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Түләүсез юридик ярдәм күрсәтү дәүләт системасы кысаларында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтүче адвокатлар хезмәте өчен түләү һәм адвокатларның түләүсез юридик ярдәм күрсәтү чыгымнарын компенсацияләү тәртибен раслау турында» 2013 ел, 21 октябрь, 774 нче карары белән расланган Түләүсез юридик ярдәм күрсәтү дәүләт системасы кысаларында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтүче адвокатлар хезмәте өчен түләү һәм адвокатларның түләүсез юридик ярдәм күрсәтү чыгымнарын компенсацияләү тәртибенә 4 нче кушымтага үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Түләүсез юридик ярдәм күрсәтү дәүләт системасы кысаларында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтүче адвокатлар хезмәте өчен түләү һәм адвокатларның түләүсез юридик ярдәм күрсәтү чыгымнарын компенсацияләү тәртибен раслау турында» 2013 ел, 21 октябрь, 774 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 20 февраль, 103 нче һәм 2015 ел, 11 март, 144 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Түләүсез юридик ярдәм күрсәтүнең дәүләт системасы кысаларында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтүче адвокатлар хезмәте өчен түләү һәм адвокатларның түләүсез юридик ярдәм күрсәтү чыгымнарын компенсацияләү тәртибенә 4 нче кушымтага түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта:

«а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) гаиләләренең уртача җан башына керемнәре Россия Федерациясе законнары нигезендә Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумы зурлыгыннан түбәнрәк булган гражданнар, керемнәре күрсәтелгән яшәү минимумы зурлыгыннан түбән булган ялгыз яшәүче гражданнар – түләүсез юридик ярдәм күрсәтүгә хокукын билгеләү өчен яшәү яисә тору урыннары буенча халыкны социаль яклау органы тарафыннан бирелгән гаиләнең җан башына уртача кереме яки ялгыз яшәүче гражданның кереме турында белешмәне;»;

«ж» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«ж) стационар формада социаль хезмәтләр күрсәтә торган социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар:

стационар формада социаль хезмәтләр күрсәтә торган социаль хезмәт күрсәтү оешмасында яшәү турында, әлеге оешмада биргән белешмәне;

медицина-социаль экспертиза федераль дәүләт учреждениесе биргән инвалидлык билгеләү фактын раслый торган белешмә күчермәсен (инвалидлар өчен);».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\164.docx